Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең
Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

04 август 2026 ел

№ 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2026 елның 04 августындагы 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге бюджетына 2024 елның 09 ноябрендәге 3 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 4 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар нигезендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге бюджетына кергән 425 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважинаны бораулауны) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау”; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тоту (юлларга асфальт салу)» өчен билгеләнгән, җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә: «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм яшәүчеләргә су бирү (скважинаны төзеклэндерү); торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (вак таш сатып алу)» җибәрү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 176 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 89 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 89 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге бюджетына 2024 елның 09 ноябрендәге 3 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 4 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Яңа Суркино авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар нигезендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Суркино авыл җирлеге

бюджетына кергән 425 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважинаны бораулауны) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау”; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тоту (юлларга асфальт салу)» өчен билгеләнгән, җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә: «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм яшәүчеләргә су бирү (скважинаны төзекләндерү); торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (вак таш сатып алу)» җибәрү белән килешәсезме? турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яңа Суркино авылы, Үзәк урамы, 12А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Иске Суркино авыл җирлеге башлыгы Е.В. Якушкин